# РӘХМӘТ, ӘНИЕМ

Әни сүзе бу дөньяда
Иң серле сүздер.
Безне саклаган фәрештә
Әни үзедер.

*Кушымта:*
Әни, әни, дип назланып
Иркәләнәбез
Кадерле, әнием сиңа
Рәхмәт әйтәбез.

Сөенсәк тә, көенсәк тә
Әниләр сизгер.
Әниләр, безнең әниләр
Алар изгедер.

*Кушымта.*

Әни кебек яратучы
Юк ул дөньяда
Иң бәхетле бала бит без
Әни, булганда.

*Кушымта.*